ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.102021 ел Баулы шәһәре №190

2022 елга Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлеше 11 пункты, Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 11 декабрендәге 201 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы 2022 елга Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга.

2. Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган норматив чыгымнар нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 29 октябрендәге
190 номерлы карары белән
расланган

2022 елга Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының типы һәм төре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Шәһәр җире | 97391 |
| | Авыл җире | 98753 |
| Общеобразовательная школа-интернат | Шәһәр җире | 143889 |
| | Авыл җире | 148363 |